ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422758 Республика Татарстан Атнинский район с. Коморгузя. Тел. 3-20-22

“12” май 2020 ел №14

**Карар**

**2017 елның 28 февраль «Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү буенча хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» 7 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 1 маендагы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 71-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Әтнә районы прокуратурасының 2020 елның 29 апрелендагы протесты нигезендә Карар бирәм:

1.«Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү буенча хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләрне раслау турында» 2017 елның 28 февралендәге 7 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1. 5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:**

«5. Иҗтимагый контроль максатларында фикер алышуны үткәрү вакыты Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә һәм әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганнан соң 5 эш көненнән дә ким булмаска тиеш.»

**2. 6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:**

«6.Заказчылар, әлеге документның 5 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, электрон яки язма рәвештә кергән иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен карый.»

**3. 7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7.Заказчылар әлеге документның 5 пунктында күрсәтелгән срок чыкканнан соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында җәмәгать контроле максатларында фикер алышу беркетмәсен урнаштыралар, ул иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның кергән тәкъдимнәрен исәпкә алу турындагы мәгълүматны һәм (яисә) заказчының кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу мөмкинлеге булмау турындагы нигезләнгән позициясен үз эченә алырга тиеш.»

**4. 8 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә**:

«8. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча, иҗтимагый контроль максатларында, заказчылар, кирәк булганда, әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларына үзгәрешләр кертү турында Карар кабул итәләр.»

**5. 12 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә**:

«12.Заказчылар агымдагы финанс елының 1 июненә кадәр әлеге документның 1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актларны кабул итәләр.

Сатып алу объектын һәм (яисә) объектларын нигезләгәндә, әлеге документның 1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр, Бюджет планлаштыруы субъектлары тарафыннан финанс органы билгеләгән тәртиптә бюджет ассигнованиеләрен бүлүне тапшырганчы исәпкә алына.»

**6. 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә**:

«13.Әлеге документның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында каралган хокукый актлар кирәк булганда яңадан карала. Күрсәтелгән хокукый актларны яңадан карау заказчы тарафыннан әлеге документның 12 пунктында билгеләнгән сроктан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»

**7.17 пунктның б пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә**:

б) Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты, казна учреждениеләре һәм бюджет учреждениеләре тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләрен) сайлап алу тәртибе (алга таба-ведомство Исемлеге));»

**8. 19 пунктның а пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә**:

«а) Товарларның аерым төрләренә карата таләпләр билгеләнә торган заказчыларның (заказчыларның) бүлекчәләре) исемнәре (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең чик бәяләре);»

**9. 9,10,11,14 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга**

10. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында : (pravo.tatarstan.ru) веб – адресы буенча урнаштырырга.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе: Ф.Ф.Низамиев